**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» июнь, 2022 ел № 379

«Сөт юнәлешендә мини-фермалар төзү» республика программасында катнашучы гражданнарга терлек азыгы сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 11 декабрендәге 1980 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон (2022 елның 14 мартына үзгәрешләр белән), Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Сөт юнәлешендә мини-фермалар төзү» республика программасында катнашучы гражданнарга терлек азыгы сатып алуга чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында» 2019 елның 11 декабрендәге 1980 номерлы карарына үзгәреш кертергә:

- Нигезләмәнең 7.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«7.2. Субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүләрне, бюджет чараларын баш бүлүче буларак һәм Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшереп тору гамәлгә ашырыла.»

- 2.4 пунктын (3 кушымтаны) яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4 Субсидияләр алучы бюджет акчаларын төп бүлүче тарафыннан субсидияләр бирүгә һәм нигезләмәнең 7.2 пунктчасында каралган тикшерүләрне муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга риза.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://pestreci.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда: «http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Д.Сабитовка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин